**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Исполнительный комитет Азнакаевского муниципаль районы**

Ленин ур., 22 й., Азнакай ш., 423330
Тел./факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы башкарма комитеты**

Ленин урамы, 22 йорт, Азнакай шәһәре, 423330
Тел./ факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

---

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

**"01" сентябрь 2022 ел** **№235**

Азнакай муниципаль районы башкарма комитетының 2020 елның 27 февралендәге 56 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының идарә органнарын, Гражданнар оборонасы көчләрен һәм гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү территориаль ярдәмче системасын әзерләү буенча оештыру-методик күрсәтмәләр турында» карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының идарә органнарын, Гражданнар оборонасы көчләрен һәм гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү территориаль ярдәмче системасын әзерләү буенча оештыру-методик күрсәтмәләр турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

2022 елның 14 июлендәге 276-ФЗ номерлы «Янгын куркынычсызлыгы таләпләре турында Техник регламент" Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында" Федераль закон нигезендә карар итә:

1. Азнакай муниципаль районы башкарма комитетының 2020 елның 27 февралендәге 56 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының идарә органнарын, Гражданнар оборонасы көчләрен һәм гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү территориаль ярдәмче системасын әзерләү буенча оештыру-методик күрсәтмәләр турында» карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының идарә органнарын, Гражданнар оборонасы көчләрен һәм гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү территориаль ярдәмче системасын әзерләү буенча оештыру-методик күрсәтмәләр турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. II бүлектәге утызынчы абзац. "Оператив әзерлек буенча чаралар" үз көчен югалткан дип танырга;

1.2. IV бүлектәге беренче абзац. "Гражданнар оборонасы буенча чараларның үтәлешен тәэмин итү буенча штаттан тыш авария-коткару формированиеләрен һәм штаттан тыш формированиеләрне әзерләү үзенчәлекләрен" яңа редакциядә бәян итәргә:

«Штаттан тыш авария-коткару формированиеләрен (алга таба - НАСФ) һәм гражданнар оборонасы буенча чараларның үтәлешен тәэмин итү буенча штаттан тыш формированиеләрне (алга таба - НФГО) төзегәндә һәм әзерләгәндә «Гражданнар оборонасы турында»1998 елның 12 февралендәге 28-ФЗ номерлы, "Авария-коткару хезмәтләре һәм коткаручылар статусы турында" 1995 елның 22 августындагы 151-ФЗ номерлы Федераль законнарга, «Гражданнар яклавы өлкәсендә халыкны укытуны оештыру турында Нигезләмәне раслау хакында» 2000 елның 2 ноябрендәге 841 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карарына, «Штаттан тыш авария-коткару формированиеләрен булдыру тәртибен раслау турында» 2005 елның 23 деабрендәге 999

номерлы Россия ГТХМ (МЧС), «Гражданнар оборонасы буенча чаралар үтәлешен тәэмин итү буенча штаттан тыш формированиеләр булдыруның типик тәртибен раслау турында» 2014 елның 18 декабрендәге 701 номерлы боерыкларына таянырга кирәк».

1.3. бишенче-ундүртенче VI бүлек абзацлары "Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы торак пунктларында янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча чаралар" 2023 елның 1 мартыннан үз көчен югалта.

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы»нда түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга: http://aznakayevo.tatar.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче А. Х. Шәмсетдинов